КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 19 июль г.Казань № 606

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе бүлекләрендә һәм филиалларында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 29 апрель, 293 нче; 2014 ел, 24 декабрь, 1020 нче; 2016 ел, 2 март, 128 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 987 нче; 2017 ел, 8 сентябрь, 642 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 820 нче; 2018 ел, 24 июль, 585 нче; 22 гыйнвар, 30 нчы; 2019 ел, 29 март, 235 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Учреждение хезмәткәрләренең иң чик штат санын вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 12 446 730 сум күләмендәге айлык фонды белән 927 берәмлек итеп билгеләргә.».

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет

учреждениесенә, Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы белән берлектә, «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесенең оештыру структурасын билгеләнгән тәртиптә билгеләгәннән соң ике ай эчендә бу карар нигезләмәләренә туры китерү өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2018 ел, 27 сентябрь, 860 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин